ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 04 2026 г. № 17

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында 2026 елның 1 апреленнән 3 апреленә кадәр матәм көне дип игълан итү турында

2026 елның 31 мартында Түбән Кама шәһәренең Гавами акционерлык җәмгыяте «Түбән Кама Нефтехим» заводы территориясендә булган шартлауның фаҗигале нәтиҗәләре белән бәйле рәвештә, һәлак булганнар өчен кайгы белдереп һәм аларның туганнары һәм якыннарының кайгысын уртаклашып, карар бирәм:

1. 2026 елның 1 апреленнән 3 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында матәм көннәре дип игълан итәргә.
2. Матәм көннәрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының бөтен территориясендә Татарстан Республикасының «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге флагын түбәнрәк төшерергә.
3. Телерадиокомпанияләргә, мәдәният, спорт, мәгариф, яшьләр сәясәте учреждениеләренә матәм көнендә күңел ачу тапшыруларын һәм чараларын үткәрмәүне тәкъдим итәргә.
4. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына Гавами акционерлык җәмгыяте «Түбән Кама Нефтехим» администрациясе белән берлектә шартлау нәтиҗәсендә һәлак булучыларның һәм зыян күрүчеләрнең гаиләләренә ярдәм күрсәтү чараларын күрергә.
5. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Башлык вазифаларын башкаручы,
Башлык урынбасары А.В. Умников

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044867